ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ

“ТУГАН ТЕЛ һӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ”

ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР (ФОНЕТИКА)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

“ТУГАН ТЕЛ һӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ”

ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР
(ФОНЕТИКА)

Казан
2024

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 августында 730 номерлы карары белән расланган «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә басыла

Төзүчеләр: Р.Р.Шәмсетдинова, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент; Р.Ф.Фәттахова, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Гыйлаҗева Л.Г., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Шакирова Г.М., Татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Bahапова Ә.Р., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы, Һадиева Г.В., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

"Татарстан республикасы дәүләт теле — татар теле" укыту предметы өчен дидактик материаллар (фонетика) / төз.: Фәттахова Р.Ф., һ.б. — Казан: ТРМҮИ, 2024. — 35 б.

Методик ярдәмлек белем бирү оешмаларында эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, мәктәп җитәкчеләренә, милли мәгариф хезмәткәрләренә тәкъдим ителә. Хезмәттә яңартылган федераль дәүләт стандартлары шартларында татар телен укыту буенча методик тәкъдимнәр бирелә, «Туган тел һәм туган тел әдәбияты» өлкәсен укытуның төп дидактик юнәлешләре һәм принцлары күрсәтелә, сөйләм компетенциясен үстерү һәм бу юнәлештә дидактик материалларны куллану үзенчәлекләре ачыклана, фонетика буенча дидактик бирем, күнегү, уен, тест үрнәкләре тәкъдим ителә.

ДИДАКТИКА һӘМ ЛИНГВОДИДАКТИКА

"Дидактика" төшенчәсен беренче тапкыр алман педагогы В.Ратке (1571–1635) куллана. 1657 елда Ян Амос Коменский Амстердамда үзенең «Бөек дидактика» хезмәтен бастыра. «Дидактика» термины — грек сүзе, didaktikos — өйрәтүче дигәнне аңлата.

Дидактика — педагогиканың аерым бүлеге, мәгариф теориясе һәм укыту технологияләре турында фән. Дидактиканың өйрәнү предметы булып белем бирү эчтәлегенең закончалыклары, принциплары, максатлары, фәнни нигезләре, формалары, укыту чаралары тора.

Дидактиканың төп бурычлары: 1) белем бирү закончалыкларын ачыклау һәм аларны белем бирү максатларына ирешү өчен куллану; 2) заманча белем бирү процессын анализлау һәм тасвирлау; 3) укытуның теоретик модельләрен эшләү һәм аларны апробацияләү; 4) белем бирү процессын оештыруның нәтиҗәле методларын һәм формаларын булдыру; 5) дәреснең методик проблемаларын анализлау һәм гомумиләштерү; 6) укучыларның өлгерешен тикшерү һәм бәяләү формаларын анализлау.

Дидактика фәне түбәндәге сорауларга җавап бирә:

Дидактик сораулар, бурычлар	*Өйрәнү объекты*
Ни өчен өйрәтергә?	Белем бирү максатлары
Нәрсәгә өйрәтергә?	Белем бирү эчтәлеге
Ничек өйрәтергә?	Укыту методлары
Укытуны ничек оештырырга?	Укыту формалары
Белем бирү ничек оештырырга?	Дәреслекләр, уку әсбаплары, дидактик материаллар, компьютер программалары һ.б.
Белем бирү нәтиҗәсен ничек бәяләргә һәм контрольдә	Тикшерү һәм нәтиҗәләрне бәяләү методлары

тотарга?	
Белем бирүдә нәрсәгә ирешергә?	Укыту нәтиҗәләрен характерлаучы критерийлар һәм күрсәткечләр
Иң нәтиҗәле белем бирү стратегиясе?	Укыту принциплары һәм аларның системасы[1]

Лингводидактика — дидактиканың бер бүлекчәсе, телгә өйрәтүнең гомуми теориясе. Бу өлкә телләргә өйрәтүнең гомуми закончалыкларын тикшерә, дидактик максатларга бәйле рәвештә, билгеле бер телгә өйрәтү методларын һәм чараларын эшли, монолингвизм (бертеллелек) яки телне үзләштерүгә билингвизм (икетеллелек) йогынтысын өйрәнә.

Россия Федерациясе халыкларының туган телләрен укыту өлкәсендә «лингводидактика» һәм «методика» терминнары бүленеше нигезендә без ике үзара бәйләнешле юнәлеш турында сөйли алабыз: 1) гомумтеоретик мәсьәләләр белән шөгыльләнә торган лингводактика (белем бирү эчтәлеге, максатлары, бурычлары, методлары, чаралары, процессы, тикшеренү методлары, укытучы һөнәренә карата таләпләр); 2) белем бирүнең конкрет шартларында конкрет туган телләргә һәм сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәтү методикасы, белем бирү процессын оештыру.

Белем бирүдә дидактик юнәлеш — методиканың төп категориясе, ул укыту стратегиясен һәм укыту методын сайлап алу ысулын билгели.

[1] В.И.Андреев. Педагогика: Учебный курс для творческого саморазвития. – 3-е изд. – Казань, 2006. – С.: 237.

«ТУГАН ТЕЛ һӘМ ТУГАН ТЕЛДӘ ӘДӘБИЯТ» ӨЛКӘСЕН УКЫТУНЫҢ ТӨП ДИДАКТИК ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Хәзерге вакытта Россия Федерациясенең гомуми белем бирү системасында төп дидактик алым булып федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезенә салынган *системалы-эшчәнлекле юнәлеш* тора. Әлеге юнәлешне куллану белем һәм күнекмәләр булдыру гына түгел, аны куллана белү, укучының шәхес үсешен, рухи-әхлакый һәм социаль тәҗрибәгә ия булун тәэмин итүне күз алдында тота.

Системалы-эшчәнлекле юнәлеш укучы шәхесенең рухи потенциалын үстерүгә, иҗади сәләтләрен ачуга, уку предметына кызыксыну уятуга корылган. Димәк, укыту процессында бу юнәлешне куллану укучыларның белем алу эшчәнлеген актив, төрле яклы, максималь дәрәҗәдә мөстәкыйль, тиешле нәтиҗәгә ирешерлек итеп планлаштыру һәм оештыруны күздә тота. Укытучы дәрестә яңа белемнәрне әзер килеш бирми, укучыларның белемнәрне “ачу” эшчәнлеген оештыра. Бу иҗади процесста укучының белем дәрәҗәсе арту, фикерләү сәләте үсү, индивидуаль шәхси үзенчәлекләре камилләшү белән берлектә аның тормышта үзенең урынын табарга мөмкинлек бирәчәк эшчәнлек сыйфатлары да барлыкка килә (ягъни универсаль уку гамәлләре формалаша): максат кую, максатка ирешү юлларын мөстәкыйль табу, эшне планлаштыру һәм оештыру, фикерли, анализлый, чагыштыра һәм гомумиләштерә белү, эш нәтиҗәләрен адекват бәяли белү, эшнең барышы һәм нәтиҗәсе өчен җаваплылык сизү, командада эшли алу, үз фикерен әйтә һәм дәлилли белү һ.б.

Системалы-эшчәнлекле юнәлештә беренче планга коллектив фикер йөртүне формалаштыра торган һәм эвристик ситуацияне конструкцияләү технологияләре алга чыга. Балаларга тәкъдим ителә торган биремнәр иҗади эш таләп итәләр: “уйлап табырга”, “төзергә”, “сайлап алырга”, “ясап куярга”, “тасвирларга”.

Педагог дәрес эшчәнлеген оештыручы: дидактик материал әзерли, укучылар белән төрле формадагы хезмәттәшлекне оештыра,

алар эшчәнлеге нәтиҗәләре турында фикер алышуда катнаша, сораулар бирә, үзконтроль һәм үзбәя бирү өчен шартлар тудыра.

Әлеге юнәлеш белем бирүдә традицион методларны инкяр итми, бары шул җирлектә яңача белем бирү максатларын тормышка ашыру юнәлешендә яңа эшчәнлек төрләрен, укыту технологияләрен куллануны алга чыгара.

Компетентлылык юнәлеше. Әлеге юнәлеш нигезендә, белем бирүнең максаты — белем, күнекмәләр җыелмасы булдыру гына түгел, ә компетенцияләр җыелмасы — укучыларның үзләре алдында барлыкка килә торган гамәли бурычларны мөстәкыйль рәвештә хәл итү сәләте булдыру. Әлеге алым кысаларында "компетенция" һәм "компетентлык" терминнары дифференциациясен (аермасын) белү мөһим. Компетенция — уку процессында алынган белем, күнекмәләр, эшчәнлек ысуллары җыелмасы. Компетентлык — билгеле компетенцияләргә ия булу. Хәзерге вакытта укучы тел һәм әдәбият өйрәнеп, лингвистик, коммуникатив, мәдәни (лингвомәдәни, этномәдәни, социомәдәни), уку, әдәби, иҗади компетенцияләргә ия булырга тиеш.

Шәхси эшчәнлек юнәлеше. Белем бирү процессында түбәндәге шартларны булдыру күз алдында тотыла:

1) укучыларның мөстәкыйль уку мөмкинлегенә зур игътибар бирү, бу исә дәреснең максатларын һәм бурычларын билгеләүдә, алар өчен уңышлы булган эш алымнарын сайлауда чагыла; 2) укучыларның төрле өлкәләрдәге булган белемнәренә таяну һәм дәрес барышында алардан файдалану; 3) укучыларның социаль-мәдәни үзенчәлекләрен һәм аларның яшәү рәвешен исәпкә алу; 4) укучыларның эмоциональ халәтен һәм аларның әхлакый кыйммәтләрен исәпкә алу; 5) укытучының дәресне оештыручы, консультант, ярдәмче, киңәшче роленә өстенлек бирү; 7) дәрестә аутентик материаллардан файдалану (уку-өйрәнү өчен төзелмәгән, ләкин уку процессында өстәмә материал итеп кулланып була торган материаллар: фәнни-популяр телетапшырулар, мультфильмнар, интервью, реклама, хатлар, җырлар, шигырьләр һ.б.).

Коммуникатив-эшчәнлекле юнәлеш. Әлеге юнәлешнең төп критерийлары:

1) телгә өйрәтүдә сөйләшергә өйрәтү максаты беренчел булу – укучыларда коммуникатив компетенцияләр формалаштыру; 2) материалны сайлап алуда һәм оештыруда функциональлек. Аралашуга корылган эшлекле биремнәрдә төрле тел берәмлекләре үзләштерелә: укучы сорау бирә, фикерне раслый, инкарь итә, шикләнә, риза була, әңгәмәдәшен ниндидер эшкә чакыра һ.б. Һәрбер очракта билгеле бер грамматик форманы үзләштерү һәм ныгыту тормышка ашырыла; 3) ситуативлык. Укыту материалын сайлаганда һәм укыту процессын оештырганда укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм кызыксынуларын искә алып проблемалы ситуацияләрне коммуникатив хәл итүгә максималь игътибар бирелә. Укучылар төрле рольләргә кереп ситуацияле уеннарда катнашалар; 4) аралашу күнекмәләрен формалаштыруга ярдәм итә торган коммуникатив биремнәрне куллану; 5) укучыларның тел ихтыяҗларын һәм аларның индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, укыту процессын индивидуальләштерү.

Мәдәни юнәлеш күбесенчә мәдәни тематикалы текстлардан файдалану аша гамәлгә ашырыла. Монда әдәби әсәрләр, фольклор текстлары, публицистик әсәрләр керә. Мәдәни юнәлеш этномәдәни тиңдәшлек (идентичность) формалаштыруга, гражданлык һәм ватанпәрвәрлек тәрбияләүгә, туган телгә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләүгә ярдәм итә. Филологик цикл предметларын өйрәнгәндә этник психология үзенчәлекләрен исәпкә алу мөһим. Укучыларны милли мәдәният белән таныштырганда, аны башка халыклар мәдәнияте белән нәрсә берләштерүенә аерым игътибар бирергә кирәк.

Социомәдәни юнәлеш юнәлеш нигезендә, телгә өйрәтү өйрәнелә торган телнең илен һәм мәдәниятен өйрәнү белән тыгыз бәйләнештә алып барыла. Аралашуга өйрәтү мәдәниятләр диалогы контекстында тормышка ашырыла.

«ТУГАН ТЕЛ һӘМ ТУГАН ТЕЛДӘ ӘДӘБИЯТ» ӨЛКӘСЕН УКЫТУНЫҢ ДИДАКТИК ПРИНЦИПЛАРЫ

Гомумдидактик принциплар. Барлык уку предметларына карата гомуми кулланыла торган принципларга түбәндәгеләр керә: фәннилек, тарихилык, активлык, күрсәтмәлелек, системалылык һәм эзлеклелек, тормыш белән бәйләнеш, укучыларның яшь һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алу. Югарыда санап үтелгән принциплар белән беррәттән, системалы-эшчәнлекле юнәлеш кысаларында эшчәнлек, даимилек, бөтенлек, минимакс, психологик комфорт, вариативлык, иҗат принциплары аерылып чыга.

Эшчәнлек принцибы буенча укучы яңа белемнәрне әзер килеш кабул итеп алмый, ә укытучы җитәкчелегендә максатчан, уку эшчәнлегенең эчтәлеген һәм формасын аңлап, нормаларын үтәп мөстәкыйль рәвештә эзләп таба һәм бу белемнәрне үзен төрле яклап камилләштерүгә юнәлдерә.

Өзексезлек принцибы укучыларның шәхси, яшь, психик һәм физиологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, укыту технологияләренең, эчтәлегенең, методикаларның бер этаптан икенче этапка күчеп баруны күз алдына тота.

Бөтенлек принцибы укучыларда дөньяны бербөтен, бердәм система итеп күзаллауны формалаштыруны алга этәрә (табигать, җәмгыять, социаль тормыш, мәдәният, кешелек дөньясы, һәрбер фәннең һәннәр системасында роле һәм тоткан урыны урыны).

Минимакс принцибы буенча мәктәп укучыга стандартлар таләп иткән кадәр (максимум) белем бирә, укучы үзенең мөмкинлекләреннән чыгып шул белемнәрне үзләштерә.

Психологик комфорт принцибы укыту процессындагы стресс тудыручы факторларны бетерү, мәктәптә һәм дәресләрдә педагогик хезмәттәшлек тудыручы, аралашуның диалогик формасын үстерүче дустанә җылы атмосфера тудыруны алга куя.

Вариативлык принцибы укучыларда вариантларны системалы рәвештә сайлый алу һәм сайлап алу ситуациясе туганда адекват карар кабул итә алу сәләтен үстерүне күз алдында тота.

Иҗат принцибы укыту процессында иҗатка максималь юнәлеш тотуны, укучылар тарафыннан шәхси иҗади эшчәнлек тәҗрибәсе булдыруны тәэмин итүне алга куя.

Россия халыкларының туган телләрен, шул исәптән туган телен (этник) белмәгән балаларны укытуда кулланыла торган төп *лингводидактик принциплар.*

Коммуникативлык принцибы. Әлеге принцип дәресләрдә реаль аралашу ситуацияләреннән файдалануны, актив иҗади эшчәнлек оештыруны, укытуның күмәк формаларын кулланууны, укучыларны гомуми эшчәнлеккә җәлеп итүне, грамматик формаларныны һәм аларның функцияләрен параллель үзләштерүне күздә тота.

Функциональлек принцибы. Яңа лексик берәмлекләрне һәм грамматик структураларны үз функцияләре белән тыгыз бәйләнештә үзләштерүне күздә тоткан методик принцип. Функциональлек принцибы телне гамәли үзләштерү юлын тәэмин итә: аралашуга корылган эшлекле биремнәрдә төрле тел берәмлекләре үзләштерелә: укучы сорау бирә, фикерне раслый, инкарь итә, шикләнә, риза була, әңгәмәдәшен ниндидер эшкә чакыра һ.б. Һәрбер очракта билгеле бер грамматик форманы үзләштерү һәм ныгыту тормышка ашырыла.

Мәдәниятара багланышлар принцибы — өйрәнелә торган телдә сөйләшүчеләрнең милли-мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып укыту-тәрбия процессын оештыру.

Минимализм принцибы. Тел, сөйләм материалларын, аралашу темаларын һәм ситуацияләрне, уку өчен текстларны сайлап алуга бәйле методик принцип. Лексик, грамматик һәм башка уку материалы минимализм принцибына нигезләнеп сайлап алына.

Уку материалын төзүнең ситуатив-тематик принцибы. Укыту материалын сайлаганда һәм укыту процессын оештырганда укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм кызыксынуларын искә алып

проблемалы ситуацияләрне коммуникатив хәл итүгә максималь игътибар бирелә. Телне өйрәнү процессы чын аралашу шартларына якын булса, укучы өчен гадәти һәм тормыш өчен мөһим булган ситуацияләр һәм аралашу темасы сайлап алынса, дәрес вакытында чын аралашу атмосферасы тудырылса, сөйләм күнекмәләрен һәм осталыкларын формалаштыру нәтиҗәлерәк була.

Аппроксимация принцибы. Укытучы, укучыларның сөйләм эшчәнлеген бәяләгәндә, телдәге һәм сөйләмдәге коммуникатив сөйләм актын бозмый торган, мәгълүмат алуга комачауламый торган хаталарга битараф кала. Әлеге принципны дөрес куллану уку аудиториясендә уңай шартлар тудыра, укучыларның сөйләм активлыгын арттыра, хаталарның куркуын бетерә.

Туган телне (татар телен) укыту процессы, алда әйтелгән гомуми дидактик принциплардан тыш, шулай ук коммуникатив технологиянең төп принципларын исәпкә алып оештырыла:

— аралашуга аралашу аша өйрәтү принцибы (телгә өйрәтү шартларын тормышта телне куллану шартларына якынлаштыру);

— шәхси индивидуальләштерү принцибы (укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру);

— телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы (аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль куллануын тәэмин итү);

— телне функциональ төстә өйрәнү принцибы (лексик-грамматик материалның коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнүе);

— ана телен исәпкә алу принцибы (балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу).

Моннан тыш, укыту процессында сөйләм эшчәнлеге төрләренә үзара бәйләнештә өйрәтү принцибы да зур әһәмияткә ия.

СӨЙЛӘМ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ҮСТЕРҮ ҺӘМ БУ ЮНӘЛЕШТӘ ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ РОЛЕ

Хәзерге вакытта туган телгә өйрәтү эчтәлеге ике төп юнәлеш белән билгеләнә: 1) традицион (лингвистик төшенчәләр, орфографик күнекмәләр, грамматиканы үзләштерү); 2) коммуникатив (телгә гамәли өйрәнүне тәэмин итә торган сөйләм күнекмәләрен формалаштыру).

Практика күрсәткәнчә, туган телдә белем бирүче оешмалар өчен төзелгән программаларда һәм туган тел дәреслекләрендә лингвистик материал өстенлек итә. Коммуникатив эчтәлек, нигездә, “Туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле” предметын өйрәнүче укучылар өчен төзелгән эш программаларында һәм дәреслекләрдә күзәтелә.

“Туган тел һәм (яки) РФ республикасының дәүләт теле” предметының эчтәлеге Россия Федерациясе субъектларының төбәк һәм этнокультура үзенчәлекләрен чагылдырырга һәм белем алучыларның коммуникатив компетенцияләрен булдыруны тиешле күләмдә тәэмин итәргә тиеш.

Мәктәпләрдә “Туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле” предметын укытуның максатлары: беренчедән, укучыларның лингвистик белемгә ия булуын тәэмин итү, ягъни татар теленең фонетик, лексик, грамматик күренешләрен практик үзләштерүгә ирешү, икенчедән, аларда коммуникатив компетенция (фикерне төпле, нигезле итеп белдерү осталыгы) формалаштыру, ягъни туган телдә аралашу, сөйләшү-аңлашу чарасы буларак өйрәтү.

Дидактик материал — укучының танып-белү эшчәнлеген активлаштыручы, аны уку процессына җәлеп итәргә, мәгълүматны кабул итәргә, бирелгән темага уйларга этәрүче материал. Дидактик материал — уку материалының үзенчәлекле төре: карта, таблицалар, текст, тестлар, карточкалар җыелмасы, шул исәптән дәресләрдә һәм өйдә мөстәкыйль эшләү өчен укучыларга бирелә торган яки бөтен

сыйныф (төркем) каршында күрсәтелә торган мәгълүмати технологияләр базасында ясалган материаллар.

Дәрес эшчәнлегендә дидактик материалны куллану укучыларның белем алу эшчәнлеген активлаштырырга, уку вакытын экономияләргә ярдәм итә. Димәк, дидактик материал телне өйрәнү өчен өстәмә уку материалы булып тора, телгә өйрәтүне мавыктыргыч, кызыклы, төрле яклы итеп оештыру чарасы буларак хезмәт итә.

Дидактик материаллар куллану максатлары:

- укучылар материалны мөстәкыйль үзләштерү һәм төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшли белергә өйрәтү;
- укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыру;
- яңа материалны мөстәкыйль рәвештә аңлый һәм үзләштерә алу;
- үзконтроль һәм үзкоррекция;
- уку материалын үзләштерү процессында күнегүләр эшләү;
- уку вакытын экономияләү;
- укуга мотивация булдыру;
- фикерләү сәләтен үстерү (теоретик, логик, иҗади, абстракт);
- укыту эшчәнлеге культурасын формалаштыру;
- тикшеренү (иҗади) уку мәсьәләләрен бергәләп хәл иткәндә интеллектуаль һәм эмоциональ функцияләр бәйләнешен активлаштыру.

Дидактик материал шартлы рәвештә берничә төргә бүленә:

- күрсәтмә материаллар: плакатлар, иллюстрацияләр, портретлар, дәреслекләргә кушымталар;
- таратма материаллар: текстлар, күнегүләр, биремнәр язылган карточкалар;
- таблицалар, схемалар, графиклар, диаграммалар;
- уеннар;
- электрон кулланмалар: видео-дәресләр, презентацияләр, электрон аудио- һәм видео китаплар;
- белешмә материаллар;
- яңа материалны өйрәнүнең логик схемасын һәм кирәкле уку-укыту ысуллары чагылдыручы инструктив карточкалар;
- биремне үтәү алгоритмы.

“ТУГАН ТЕЛ һӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ” ПРЕДМЕТЫН ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАРГА ФОНЕТИКАНЫ ӨЙРӘТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Телне өйрәнү сүзнең фонетик ягын өйрәнү белән тыгыз бәйле. Фонетика телнең матди ягын тәшкил иткән барлык тавыш чараларының (аваз, ритм, мелодика, интонация, паузалар) бергәлеген тәшкил итә. Фонетика — тел белеменең бер бүлеге. Фонетика телдәге авазларны, аларның әйтелешен, язылышын өйрәнә, сөйләмдәге авазларның үзгәрешен тикшерә.

Дөрес әйтү күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү — татар теленә чит тел буларак өйрәтүнең максаты булып тора. Татар әдәби әйтелеш нормаларыннан төрле тайпылулар, шул исәптән, аерым хәрефләрне дөрес әйтмәү әңгәмәдәшнең сөйләмен аңлауны кыенлаштыра, яисә әйткәннең мәгънәсен аңламауга китерә.

Әйтелешкә өйрәтүдә авырлык *интерференция* күренеше белән аңлатыла. Чит телнең аваз формасы туган телнең сөйләм күнекмәләре нигезендә өйрәнелә, шул сәбәпле чит тел һәм туган тел күренешләренең туры килүе яки аермасына бәйле рәвештә төрле кыенлыклар туа. Ике телдә дә бер төрле әйтелешле авазларны үзләштерү җиңелрәк. Туган телдә аналоглары булмаган авазларны әйтергә өйрәнү катлаулы процесс.

Рус балаларын сөйләшергә өйрәткәндә, әйтелешне камилләштерү мәсьәләсе зур әһәмияткә ия, чөнки сөйләү авазлар ярдәмендә белдерелә. Татар һәм рус теленең авазлар төзелеше арасындагы аермаларны исәпкә алырга кирәк. Татар телендә рус теленең кайбер авазлары юк, аның каравы, рус телендә булмаган авазлар ([ә], [ө], [ү], [ң], [җ], [һ]) татар телендә бар. Балаларның авазларны дөрес әйтүләренә ирешү өчен, рус һәм татар теленең авазлар системасын, андагы охшашлыкларны һәм аермалы якларны белергә кирәк.

Татар теле агглютинатив телләр рәтенә керә, рус теле – флектив. Татар телендә рус теленә караганда сузыклар күбрәк. Татар

сузыклары тәңгәл рус сузыклары белән чагыштырганда тел алдындарак ясалулары белән аерылып тора. Сузык авазларны тикшергәндә, без аларның рус һәм татар телендә ясалу ысулына игътибар итәбез.

Рус телендә

Күтәрелеш	алгы рәт		урта рәт		арткы рәт	
	ирен-ләшкән	ирен-ләшмәгән	ирен-ләшкән	ирен-ләшмәгән	ирен-ләшкән	ирен-ләшмәгән
Югары		и		ы	у	
Урта		э			о	
Түбән				а		

Татар телендә

Күтәрелеш	алгы рәт		урта рәт		арткы рәт	
	ирен-ләшкән	ирен-ләшмәгән	ирен-ләшкән	ирен-ләшмәгән	ирен-ләшкән	ирен-ләшмәгән
Югары	ү	и			у	ы
Урта	ө	э			о	ы
Түбән		ә				а

Татар телендә 9 сузык һәм тагын алынма сүзләрдә кулланыла торган 3 сузык ([о], [э], [ы]) бар.

Тартык авазлар

Рус һәм татар телләрендәге тартыклар бер-берсеннән ясалу урыннары һәм әйткәндә сөйләм әгъзалары катнашу белән аерылалар. Татар телендә тартыклар:

- ясалу урыны;
- ясалу ысулы;
- тавыш катнашу яки катнашмау буенча бүленәләр.

Рус телендә түбәндәгечә:

- ясалу урыны;
- ясалу ысулы;
- тавыш катнашу яки катнашмау.

Татар теленең тартыгы 23 билгегә ия. Ясалу урыны буенча: ирен, ирен-ирен, ирен-теш; тел, тел-теш, тел-аңкау, тел уртасы, тел арты, кече тел (увуляр), йоткылык (фарингаль), бугаз (ларингаль).

Ясалу ысулы ягыннан: йомык, саф, аффрикат, өрелмәле, ярым-йомык, борын, ян-як, калтыраулы.

Акустик аспект буенча: шаулы, сонор, яңгырау, саңгырау.

Рус теле тартыклары 14 билге буенча аерыла. Ясалу урыны ягыннан: ирен, ирен-ирен, ирен-теш; тел алды, тел-теш, тел-аңкау, тел уртасы, тел арты, урта аңкау, арткы аңкау. Ясалу ысулы буенча: йомык, аффрикат, өрелмәле, калтыраулы.

Татар телендә 26 тартык, алынма һәм диалект сүзләр составында кулланыла торган 5 тартык ([ц], [ᵀч], [щ], [в], [х]), 25 тартык фонема һәм рус алынмаларыннан күчкән 3 фонема ([в], [ц], [щ]) бар. Татар теленең үзенә генә хас булган тартыклары: [къ], [гъ], [ң], [җ], [һ], [,].

Рус телендә төп авазлар һәм фонемалар бер үк санда: 6 сузык һәм 35 тартык бар. Рус телендә тартыклар ике вариантта: калын, нечкә. [ч], [щ], — һәрвакыт нечкә, [ц], [ш] — һәрвакыт калын була.

Димәк, татар һәм рус телләрендәге тартыклар бер-берсеннән ясалу урыннары һәм сөйләм әгъзаларының катнашуы белән аерыла. Фонетик күнегүләр эшләгәндә без бу күренешне сизәбез. Мәсәлән, үзенчәлекле [һәмзә] тартыгы өчен татар алфавитында махсус урын юк, ул ь, э хәрефләре ярдәмендә белдерелә: тәэмин, мәсьәлә.

Укучыларның игътибарын өйрәнелә торган телнең фонологик үзенчәлекләренә юнәлтү өчен, аны балаларның ана теле белән чагыштырып өйрәтү мөһим. Бу укучыларга өйрәнелә торган телнең үзенчәлекләрен үзләштерергә һәм шуның белән бер үк вакытта туган телгә тирәнрәк үтеп керергә ярдәм итә. Төрле телләрдә бер үк фикерне төрлечә әйтү үзлеге булуын аңлау укучыларның дөньяга карашын киңәйтә һәм һичшиксез гомуми белем бирү мәгънәсенә ия була.

ФОНЕТИКАДАН ДИДАКТИК БИРЕМНӘР

Дөрес әйтү күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү — татар теленә чит тел буларак өйрәтүнең максаты булып тора. Татар әдәби әйтелеш нормаларыннан төрле тайпылулар, шул исәптән, аерым хәрефләрне дөрес әйтмәү аңгәмәдәшнең сөйләмен аңлауны кыенлаштыра, яисә әйткәннең мәгнәсен аңламауга китерә. Мондый балаларга сүздәге авазлар санын билгеләргә, бирелгән авазлар белән сүзләр төзергә кыен була һәм сөйләм дәрәҗәсенең түбәнлегенә китерә. Фонематик яктан ишетеп аеру сәләте формалашмаган балаларга дөрес язу күнекмәләре кыен бирелә.

Әдәби әйтелеш нормаларына өйрәтү мәктәптә уку дәвамында башкарылырга тиеш, ләкин аның нигезе башлангыч классларда ук салына. Төп бурыч әйтелештә булган кимчелекләрне бетерүдән генә тормый, ә бәлки аларны алдан ук кисәтергә кирәк, чөнки бу эшне соңыннан төзәтүгә караганда шактый җиңелрәк. Татарча әйтелешкә өйрәтүдә очраган авырлыклар төрле метод һәм алымнар ярдәмендә юк ителә алуын истә тотып эшләргә киәк. Теге яки бу методны куллану белем бирү, үсеш һәм тәрбия максатларыннан чыгып билгеләнә.

Мәктәп практикасы дәлилләгәнчә, әйтелеш хаталарының зур күпчелеге рус теленең авазлар төзелеше үзенчәлекләре, аерым алганда, татар теленең аңардан фонетик-орфоэпик өлкәдә шактый аерылып торуы белән бәйле. Туган телдә барлыкка килгән әйтелеш күнекмәләре укучылар хәтерендә ныклап сакланып кала ала, һәм бу алдагы классларда сөйләүдә озак вакытлар сакланып кала торган үзенчәлекле акцентның барлыкка килү сәбәбе дә булып тора. Димәк, татарча әйтелешкә өйрәтү беренче дәресләрдән үк һәм мәктәптә укыту дәвамында өзлексез алып барылырга тиеш. Төп күнекмәләр башлангыч сыйныфларда булдырыла, ә алдагы сыйныфларда укучыларның әйтелеш осталыклары камилләшә бара һәм аңлы төстә башкарыла башлый. Бер-ике авазның хаталы әйтелеше нигездә сүзнең мәгънәсен үзгәртә ала (мәсәлән: күл/кул). Татар телен

өйрәнгәндә, беренче чиратта фонемаларның дөрес әйтелешен үзләштерегә кирәк. Шуның белән бергә, татар теленең авазларын аерым гына яңадан әйтә алу белү осталыгы һәрчак дөрес әйтелешнең гарантиясе булып та тормый әле. Авазларның дөрес әйтелеше сыйфатын сөйләм барышында гына билгеләп була.

Авазларны тану һәм аеруга юнәлдерелгән күнегүләр

Сүзнең фонематик ягын аеру — сөйләмнең аваз составын аеру һәм сөйләмдә сүзләрнең мәгънәсен аңлау сәләте ул.

Татарча әйтелешкә өйрәтүдә түбәндәге дидактик күнегүләр нәтиҗәле:

— татар һәм рус сүзләренең әйтелешендәге охшашлык һәм аерманы табу, төп игътибарны аларның мәгънәсенә юнәлтү өчен, *бәр-бар, кул-күл, түк-тук, сүз-суз, көч-коч* кебек сүзләрне әйтеп, русчага тәрҗемә итү;

— өйрәнелгән фонемалар белән сүзләр уйлау. Мәсәлән: [ө] сузыгы белән: *өн, көн, төн, өм[ө]т, төт[ө]н, бөт[ө]н* һ.б.;

— авазны аерым һәм сүз составында әйтеп карау: *[ә]: әкият; [ө]: көз; [ү]: күз; [җ]: җәй; [ң]: яңа; [һ]: һава;*

— өйрәнелә торган фонетик күренешкә махсус сайланган сүзләрне һәм җөмләләрне уку;

— фонетик таблицалар белән эшләү;

— өйрәнә торган авазлар кергән табышмаклар чишү, тизәйткечләр, саналмышлар, шигырьләр ятлау һәм аларны әйтү.

Укытучы укучыларга төрле авазлар кергән сүзләрне, фразаларны, рифмовкаларны тыңларга тәкъдим итә. Биремнәр шундый булырга мөмкин:

— озын яки кыска авазны ишеткәч, кул күтәрегез;

— җөмләдә ничә тапкыр [] авазы очрый, шул сан язылган карточкаларны күтәрегез;

— [ ] һәм [ ] авазлары кергән сүзләрне тыңлагыз. Кызыл карточканы [ ], яшелен [ ] авазын ишеткәч күтәрегез.

Татар сүзләрендә авазларны тану һәм аеру өчен төрле дидактик биремнәр тәкъдим ителә. Мәсәлән, калын һәм нечкә сузыкларны аера белү күнекмәсен булдыруга юнәлгән биремнәр: сүздәге калын сузыкны нечкә пары белән алмаштырып сүз ясау; калын һәм нечкә әйтелешле авазларны табу; кушылмаларның калын һәм нечкә парларын табу; хәрефләрне чиратлаштырып сүзләр ясау.

Сузык авазлар астына бер сызык, тартык авазлар астына ике сызык сызыгыз.

Болыт мин —
Һавада,
Яңгыр мин —
Яуганда.

Тик торсам —
Күлдәвек,
Йөгерсәм —
Гөрләвек.

Җылынсам — Пар булам,
Туңганда — Кар булам.

Ә таңда
Чык булам,
Тамгачтын —
Юк булам...
(Р.Миңнуллин «Табышмак»)

Шигырьдән башта сузыкка башланган, аннан соң тартыкка башланган сүзләрне сүзләрне күчереп языгыз.

Җәйләр яшел,
Кышлар ак.
Бездә шундый
Туган як.

Көзен сары,
Алтындай.
Янып торган
Ялкындай.

Ә нинди соң
Гөлле яз?
Аңа бөтен
Төсләр хас.
(Мөҗәһит. «Шундый туган як»)

Калын сузык авазлар астына бер сызык, нечкә сузык авазлар астына ике сызык сызыгыз.

Кинога барган чакта,
Әтиемне яратам.
Тәмләп-тәмләп ашаганда,
Әниемне яратам.
Ә абыем ачуланса,
Мин апамны яратам.
Дәрес хәзерләгән чакта,
Абыемны яратам.
Күрше малае кыйнаса,
Әбиемне яратам.
Әкият сөйләгән чагында,
Мин бабамны яратам.
(Р.Вәлиев. «Барысын да яратам»)

Татар телендә генә булган авазлар кергән сүзләрне табып языгыз (астына сызыгыз) һәм укып күрсәтегез.

Буа өстендә Каз йөзеп йөри. Үзе белән үзе сөйләшә-сөйләшә йөзә.

— Гаҗәп тә кош инде үзем. Җиргә басып та йөрим, суда да йөзәм, һавада да оча алам. Дөньяда андый кошны табып кара әле. Мин бит кошлар патшасы! — ди.

Каз сүзләрен Торна ишетеп торган икән. Торна казга әйтә:

— Ахмак та кош син, Каз! Я, чуртан кебек йөзә аласыңмы? Болан кебек йөгерә, лачын кебек оча аласыңмы? Бар нәрсәне әз-мәз белгәнче, бер нәрсәне бик яхшы белүгә ни җитә, — ди.

(К.Ушинский. «Каз белән торна»)

Бу сүзләрнең азагында нинди аваз ишетелә?

Үз, күз, түз, без, сез, йөз, өз, күзсез, безсез, телсез, нигезсез.

Йөзә, түзә, сөзә, сизә, изә.

Илнур ил гизә. Илүзә камыр изә.

Син өйне бизә.

Бу сүзләрнең беренче авазлары нинди?

Заман, зур, Зариф, зирәк, зиһен, Зөһрә, зыян, зифа, зырылдый, зарланма.

Татар сүзләрендә аерым авазларны таптыру, бу сүзләрне дөрес итеп уку өчен түбәндәге биремнәр отышлы:

Ничә “Ч”?

Җәй көнендә кичкә таба

Чалгы белән печән чаптым.

Печән чабам дигән булып,

Чиләк чиләк җиләк җыеп,

Чәчәкләргә чумып яттым.

Бер ач мәче тычкан аулый,

Ә тычкан аны алдый.

Ул тычканның качалмасын

Мәче барыбер аңлый.

Ничә “Ж” бар?

Жираф белән

Бер аждаһа

Күргән идем.
Яннарыннан
Выжлап узып
Йөргән идем.
Курыкмадым,
Йөрәгем дә
Жу итмәде.
Мүлтине күп
Карыйм бит мин:
һуш китмәде.

“һ” авазы
һоп-һоп, туп һавага сикерә
һоп-һоп, Бәһау туплы уйный
“һау-һау” диеп этләр өрә.
Тәһир һаман шәһәрне сагына.
һавада бер торна күрдем.
“һәш-һәш” диеп мал куалар.
Зөһрә, зәһәр, Мәһди.

(Мөҗәһит)

Тизәйткечләр – беренче карашка әйтелешләре авыр булган, бер-берсенә охшаш сүзләр җыелмасы. Тизәйткечләрне укымыйлар, ә кеше әйтүе буенча кабатлыйлар. Тизәйткечләр – авазларны дөрес әйтү өчен генә түгел, баланың дикциясе өчен дә файдалы күнекмә булып тора. Алар артикуляцион аппаратны бер халәттән икенчесенә тиз кучерергә, авазларны ачык итеп әйтергә ярдәм итәләр, кызыклы уен формасы да булып торалар. Билгеле бер авазның әйтелешенә шул аваз еш кабатланган сүзләр булган тизәйткечләр кулланыла.

[а]:

Абагага бага-бага, башым бәрдем баганага.
Андый төймә Ләбибәдә дә бар, Нәфидәдә дә бар.

[ә]:

Әрәмәдәге әрем әче.

[ү]:

Күп күркәгә кирәк күп көрпә.

[ө], [ү]:

Биш үгездә

Биш мөгез.

Әй саташтым,

Ун мөгез.

Ун үгездә

Ничә мөгез,

Мүкләк булса

Өч үгез?

Санагызчы

Үзегез,

Әгәр җитсә

Көчегез.

[җ]:

Җиләк җыя Җәмилә.

Җылы җәйнең көннәрендә Җәймә тау итәгендә Җизни кызы Җәүһәрия Җиләк җыя чиләгенә.

Җиләк, җиләк,җиләкләр,

Бик тиз тулмый чиләкләр.

Тулыр иде чиләге,

Юк бит аның җиләге.

[h]:

Илһам җырлый, илһам килсә,

Илһамның бар аһәңе.

Илһам абый белә микән

Халык биргән бәһане.

[къ]:

Капкага капка каршы, Капкага капка капма-каршы.

[т]:

Талга кунар бер тартар, Ул тартарны тал тартыр,

Тартар басып талны тартыр,

Тал тартыр, тартар калкыр,

Тартар калкыр, тал тартыр.

[с]:

Синең мускул мускулмыни, мускул түгел ул — мыскыл. Менә Мостафа мускулы мускул дисәң дә мускул.

Сыерчык, сыерчык,

Нинди матур сызгырчык!

[ш]:

Дару белән өч шешә,

Шешә бавын теш чишә, шешә чишсәң теш шешә.

Татар теле дәресләрендә сүзләрнең дөрес әйтелешен өйрәтүдә уеннар зур роль уйный.

Фонетик уеннарның төп максаты — әйтелешне коррекцияләү, дөрес интонация белән сөйләшергә өйрәтү.

Фонетик уеннарның бурычлары күптөрле:

— укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү;

— фонематик ишетү һәм артикуляцион күнекмәләр формалаштыру;

— сөйләм һәм аудирование күнекмәләрен камилләштерү;

— мөстәкыйль сөйләм эшчәнлегенә психологик әзерлек;

— укучыларда өйрәнелә торган предмет белән кызыксыну уяту һәм уңай мотивация булдыру.

Бу уеннар дәрестә яхшы разрядка алу өчен дә файдаланыла ала, иркенлек атмосферасын тудыра.

Аерым билгеләр буенча сүзләр табу (беренче аваз, хәреф һәм иҗек буенча; бирелгән тема буенча; рәсем буенча; соңгы хәреф буенча; синонимнар, антонимнар табу).

Сүзләрне тергезү (төшеп калган хәрефләрне кую; таралган хәрефләрне тиешле тәртиптә урнаштыру; таралган сүзләрдән

җөмләләр төзү; яңа сүз ясау өчен хәрефләр (иҗекләр) өстәү яки алып ташлау).

Алып баручы (яхшы өлгерүче укучы) уенда катнашучыларга чираттан аваз әйтеп туп ыргыта (мәсәлән, [к]), катнашучылар әлеге аваз булган сүзне әйтеп ([кар]), тупны кире кайтаралар.

Укытучы тактага кыска гына сүз яза. Аның астында язылган икенче сүз бер хәрефкә озынрак булырга тиеш.

«Сүзләр чылбыры»

Укытучы бер үк төрле аваз ишетелә торган сүзләр чылбыры әйтә (әни, әти, бәби, тәлинкә, күркә, чәйнек), беренче булып ([ә] авазын) җавап тапкан бала үзенең табышмагын әйтү хокукын ала.

«Агент»

Уенда ике команда катнаша. Уенда катнашучылар яшерен агентның серле кодын чишәргә тырыша. Һәр цифр — билгеле бер алфавит хәрефе. Мәсәлән, А-1, Ә-2, Б-3 һ.б.

«Телефон»

Тактада зур телефон рәсеме ясала. Дискта саннар урынына хәрефләр языла. Укучылар билгеле вакыт аралыгында күбрәк итеп (специфик татар авазларын кулланып) сүзләр җыярга һәм аларны әйтергә тиешләр. Мәсәлән, әни, һәм, кар, өстәл, үрдәк, чәйнек, чиләк, җиләк һ.б.

«Баскыч»

Уенда катнашучылар сыйныф тактасында сүзләрдән баскыч төзиләр. Һәр сүз алдагы сүзнең соңгы хәрефеннән башланырга тиеш.

«Анаграммалар»

Уенда хәрефләр тәртибен үзгәрткәч, яңа сүз килеп чыга торган сүзләр кулланыла. Уйнаучылар укытучыдан шундый сүзләр белән карточка алалар.

«Төшеп калган сузыклар»

Укытучы тактада тартык хәрефләр яза. Укучылар, җитешмәгән сузыклар өстәп, сүзләр ясыйлар.

«Нинди сүз кабатланды?»

Укытучы (яки укучы) дәрестә өйрәнелгән сүзләрне әйтә. Бер сүз ике мәртәбә әйтелә. Укучылар, аны табып, әйтергә тиеш була.

«Шахмат»

Укытучы укучыларга төрле авазлар сурәтләнгән өстәл картасын һәм йөреш ясау өчен "пешкалар" тәкъдим итә. Укучылар коллектив эшлиләр. Һәр укучы хәрәкәт ясый һәм әлеге авазга 2 сүз атый. Финалга тизрәк барып җиткән кеше җиңүче булып тора.

«Җөмләдә ничә сүз бар?»

Укытучы җөмләләр укый. Укучылар җөмләдә сүзләр санын билгеләргә тиеш.

Шундый ук уенны сүздәге иҗекләр санын, яисә текстта ничә җөмлә барлыгын билгеләү өчен дә үткәрергә мөмкин.

«Сүзләр яса»

Укытучы ашыкмыйча гына авазлар әйтә, укучылар алардан сүз төзеп әйтергә тиеш. Мәсәлән, *ө-с-т-ә-л – өстәл, к-и-т-а-п - китап* һ.б.

«Беренче аваз»

Укытучы сүзләр әйтә, укучылар аларның беренче авазларын кабатлый. Мәсәлән: *урындык, үрдәк, кул, күл, әтәч, алма* һ.б.

Бу уенны сүзләрнең соңгы авазларын билгеләү өчен дә үткәрергә мөмкин.

«Ничә сузык аваз?”

Укытучы сүзләр әйтә, укучы алардагы сузык авазларны билгеләп, ничә тапкыр очраганнарын әйтергә тиеш була. Мәсәлән: *балалар, мәктәптә, өченче, солы, булу.*

«Эстафета»

Укытучы парлы сүзләр әйтә. Мәсәлән, *оч-өч, бара-бәрә, тоз-төз, кул-күл, була-бүлә.* Укучылар башта каты, аннары йомшак әйтелә торган тартыкларны әйтәләр. Балаларның әзерлек дәрәҗәсеннән чыгып, сүзләрне руссчага тәрҗемә иттерергә дә була.

«Бу нинди сүз?»

Укытучы тактага сүзләр һәм аларның тәрҗемәсен яза. Укучылар сүзләрне игътибар белән карарга һәм истә калдырырга тиеш. Укытучы берничә секундтан соң сүзләрне сөртә һәм һәр рәттән, яки

командадан укучыларны чакыра. Аларның һәркайсы барлык сүзләрне тәрҗемәсе белән әйтергә тиеш була. Барлык сүзләрне, аларның тәрҗемәсен хатасыз әйтә алган команда җиңүче була.

“Тере чайнворд”

Укучылар алдан әйтелгән сүзнең соңгы хәрефләренә башланган сүз уйлап табарга тиеш. Мәсәлән, *китап — парта — акбур — ручка* һ.б.

“Кем тизрәк?”

Укучыларга парлы сузык авазларны әйтергә тәкъдим ителә. Икенче этап — калын һәм нечкә сузыклар белән иҗекләр әйтү.

“Сүзләр уйлап табу”

Укучылартөрле авазларга башланган, мәсәлән, [а], [ә], [о], [ә] сузыклары белән татар сүзләре (татарча кеше исемнәре, кош, үсемлек атамалары һ.б.) уйлап әйтәләр.

“Аерма нәрсәдә?”

Укытучы сүзләр әйтә, ә укучылар сүзләрне бер-берсеннән аера торган фонемаларны билгеләргә тиеш була. Мәсәлән: *аш, ат, аз, ал, ак, им, ас, ач, аң, ах; ул, ук, уз, уң, ур, ут, уч, ух* һ.б.

“Орфографик чылбыр“

Бу күнегүне сүзләр чигендә хәрефләрнең әйтелеше үзгәрүенә игътибарны юнәлтү өчен кулланырга мөмкин. Сыйныф ике командага бүленә. Укытучы бер хәреф әйтә, командадан бер укучы чыгып, шул хәрефкә башланган сүз язып куя, икенче командадан бер укучы чыгып, беренче укучы язган сүзнең ахыргы хәрефенә башланга икенче сүзне яза. Һәр яңа сүз алдагы сүзнең соңгы авазыннан башланырга тиеш. Һәр дөрес сүз командага очко китерә, уен сүз беткәнче дәвам итә.

Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм басымны билгеләү

Иҗек — әйтелешнең иң кечкенә берәмлеге. Ул тактның бер яки берничә аваздан торган кисәге. Иҗек составында бер, ике, биш аваз да булырга мөмкин. Һәркем иҗекләргә бүлеп әйтә белүгә карамастан, иҗеккә билгеләмә бирү һәм аның чикләрен билгеләү фонетиканың катлаулы мәсьәләреннән санала.

Басым сөйләмнең бер кисәген башкаларыннан аерып кую өчен хезмәт итә торган элемент. Һәрбер телдә басымның теге яки бу төре өстенлек итә. Рус, инглиз, төрки телләрдә көч басымы таралган, рус телендә микъдари басымы да катнаша.

Басым ижек составындагы сузык авазга төшә. Төрки телләрдә, аерым алганда татар телендә, басым соңгы иҗеккә омтыла, сүзгә кушымчалар ялганганда да, басым ахыргы иҗеккә күчә бара: урман — урман-чы, урман-чы-лык. Ләкин бу кагыйдәдән чыгармалар да бар:

— икенче зат боерык фигыльләрдә басым беренче иҗеккә төшә: языгыз, утырыгыз;

— исемдә хәбәрлек кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: мин укучымын, сез бәхетлесез;

— фигыльдә кайбер зат-сан кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: язгансың, килермен;

— фигыльдә юклык кушымчасы басымны алмый һәм үзеннән үткәрми: баргансың — бармагансың;

— рәвеш ясагыч -дай/ -дәй, -тай/ -тәй, -ча/ -чә кушымчаларына басым төшми: бүредәй, татарча;

— сорау, билгеләү, юклык алмашлыкларында, өлешчә күрсәтү һәм билгесезлек алмашлыкларында басым беренче иҗеккә тешә: кайда, барлык, һичкем;

— кайбер гарәп-фарсы алынмаларында басым алдагы иҗеккә төшә: әлбәттә, ләкин, һәммә;

— китап теле, язма тел аша кергән рус алынмаларында басым саклана: республика, опера, демократия.

Шулай да аларга кушымчалар ялганганда, ике төрле үзгәреш була:

— басым соңгы иҗектә булса, ул кушымчаларга күчә бара: диктант, диктантлар, диктантларга;

— әгәр басым алдагы иҗектә булса, ул, гадәттә, урынында кала: аренда, арендачы, арендаларга.

Сүзләрне укыгыз. Сүздә ничә иҗек булуын әйтегез.

Ат, ана, Әминә, алабуга, сыйныфташлар.

Сүзләрне укыгыз. Иҗекләргә бүлеп күчереп языгыз.

Ел, сәгать, вакыт, минут, атна, ай, көн, секунд.

Сүзләрнең иҗекләрен алыштырып, яңа сүз ясап языгыз.

Таба – бата, каба — ..., куба — ..., кесә — ..., чабак — ..., дару — ..., акбаш — ... .

Бер иҗекле сүзләрдән ике иҗекле яңа сүзләр ясагыз.

Яз — язгы, кыш — ..., күз — ..., су — ..., җыр — ..., баш — ..., сүз —... .

Иҗек саны үзгәрмәслек итеп, сүзгә бер хәреф өстәп языгыз.

Аш — таш, ат — ..., ай — ..., илək — .... азык — ..., порт — ..., ун — ...

Сүзләрне укыгыз, иҗекләргә бүлеп языгыз. Иҗекләргә бүлү кагыйдәсен аңлатыгыз.

Аю, корт, чәчәк, иҗек, кош, күгәрчен, өстәл, урындык.

Бер баганага бер иҗекле, икенче баганага ике иҗекле, өченче баганага өч иҗекле сүзләрне иҗекләргә бүлеп языгыз. Сузык авазларның астына сызыгыз.

Поши, эт, күгәрчен, корт, каз, төлке, бүре, кош, сандугач, куян, сыерчык, ябалак.

Текстгагы сүзләрнең ничә иҗекле булуын билгеләгез.

Бер Аю имән башына бал куйган. Аны Мәче сизгән һәм имән башына менгән. Мәче бал ашап торган чакта, Аю килгән дә:

— Монда нишлисең? — дигән.

Мәче әйткән:

— Менә аюларны, бүреләрне зоопаркка җыярга килдем, — дигән.

Аю, бу сүзләрне ишеткәч, имән башыннан төшкән дә качкан. Мәче дә, Аюдан куркып, икенче якка чапкан.

(Татар халык әкияте. «Мәче белән Аю»)

Сүзләрне үстерегез, иҗеккә бүлеп языгыз.

Таба — табак, бүре — ..., шар — ..., сары — ..., капка —..., метр — ..., арка — ... .

Сүз басымы беренче, икенче, өченче, дүртенче иҗекләргә төшкән сүзләрне баганлап языгыз.

Яратыгыз, киткәннәр, нәрсә, нигә, кайта, авылдашлар, сыйныфташларыгызмы, киләчәкме, баралар, әнә, язамы, ишетелерме, беркемне, көнкәнсездер, ишеткәнчә, күргәнегезчә, татарча, русча, карамагыз, теләмибез, күрешербез, кайтыгыз, минемчә.

Сүз басымын дөрес куеп, сәнгатьле итеп укыгыз. Басымның соңгы иҗеккә төшмәгән очракларын аңлатыгыз.

Кичке тынлык. Сәгать келт-келт
Вакыт саный — туктамый.
Курчаклар да ял итәләр,
Йолдыз гына йокламый.
— Нишләп соң борсаланасың,
Авырта, — дим, — кай җирең?..
Керфекләре йомылганнар,
Кыймылдый чак-чак ирен:
— Юк, авыртмый. Акбай гына
Йокласын, өрмәсен, ди.
Сәгать тә ялга туктасын,
Сукмасын, йөрмәсен, — ди.

(Вил Казыйханов. «Сәгать ялга туктасын»)

Йомгаклап әйткәндә, фонетик уен күнегүләре әйтелештәге хаталарны бетерергә ярдәм итә, татарча сөйләмне аңлауны җиңеләйтә, телне өйрәнүгә кызыксынуны арттыра.

Дидактик тест — хәзерге белем бирү системасының иң еш кулланыла торган тикшерү формасы. Тест ярдәмендә укучыларның белемнәрен тикшерү махсус төзелгән тест биремнәре буенча оештырыла. Укыту тестларының максаты – укучыларның аралашу һәм тел компетенцияләренең дәрәҗәсен билгеләү. Тест сораулары берничә вариантта эшләнә. Алардагы биремнәр логик эзлеклелектә, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелә. Укучыларга белем бирү, фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру, тәрбияләү процессында тестлар куллану мәгълүматны кабул итү, игътибарны көчәйтү, хәтер һәм интеллектны үстерүдә югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирә; кешенең ми эшчәнлеген, уйлау сәләтен активлаштыра. Дәрестә даими рәвештә тест уздыру укучыларның активлыгын һәм игътибарын үстерә, биремнәрне үтәгәндә, аларның җаваплылыкларын арттыра.

Тестның башка тикшерү формаларыннан түбәндәге өстенлекле яклары бар:

— белем һәм күнекмәләрне үзләштерү сыйфатын тикшерү тизлеген арттыра;

— уку материалын тулысынча кабатларга ярдәм итә;

— контроль нәтиҗәләрен математик-статистик эшкәртү мөмкинлеге барлыкка килә һәм, нәтиҗә буларак, педагогик тикшерүнең объективлыгын арттыра;

— адаптив тестларны куллану ярдәмендә индивидуальләштерү һәм укытуны дифференциацияләү принцибын гамәлгә ашыру мөмкинлеге барлыкка килә.

Тест биремнәренең түбәндәге төрләре була:

№	Тест төрләре	Үзенчәлекләре
1.	Тәңгәлләштерү	Уртак темалар яки башка билгеләр буенча берләшкән ике блоктан парлар сайлау.
2.	Альтернатив сайлау	Текстның эчтәлегенә бәйле рәвештә

		"әйе”/”дөрес”/”туры килә" яки "юк”/”дөрес түгел”/”туры килми" дип җавап бирү.
3.	Дөрес вариант(лар) сайлау	Бирелгән берничә җаваптан бер яисә берничә дөрес вариантны сайлау.
4.	Тәртипкә салу	Аерым репликалардан яки җөмләләрдән текст, диалог төзү.
5	Артык берәмлекне билгеләү	Бирелгән сүз/ сүзтезмә/ җөмлә төркемендә тема яки башка билгеләре буенча туры килмәгәнен билгеләү (алып ташлау, сызу).
6.	Тәмамлау	Мәгънәгә нигезләнеп җөмләне тәмамлау.
7.	Хата төзәтү	Сүз формасында яки җөмләнең структурасында киткән грамматик һәм сөйләм хаталарын төзәтү.
8.	Үзгәртү	Үрнәк нигезендә җөмләне үзгәртү.
9.	Эчтәлекне тәкъдир итү	Текстның эчтәлеген яки мәгънәсен үз сүзләрең белән тапшыру.
10.	Тәрҗемә итү	Тәрҗемә итү.
10.	Клоуз-тестлар	Укучы бирелгән текстта төшеп калган элементларны торгызу.

Алга таба дидактик тест төрләренә мисаллар китерелә.

1. а) Хәрефләр белән цифрларны тоташтырып, сүзләрнең ничә аваздан торуын билгеләгез.

1. ямьле а) 3
2. яшьлек ә) 4
3. яшь б) 5
4. июнь в) 6
5. игътибар г) 7
6. юлбарыс д) 8

б) Хәрефләр белән цифрларны тоташтырып, сүзләрдә нинди аваз төшеп калуын билгеләгез.

1. ...ава а) [х]
2. ..ат ә) [һ]
3. һ...җүм б) [ә]
4. һ..йкәл в) [ө]

5. хәт..р г) [и]

6. тар...х д) [е]

2. а) Калын сузык авазны билгеләгез.

а) [ы];

ә) [э];

б) [ә];

в) [и].

б) Саңгырау тартык авазны билгеләгез.

а) [в];

ә) [д];

б) [з];

в) [h].

в) Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез.

а) *татарча*;

ә) *ничәнче*;

б) *ашаганчы*;

в) *укытучы*.

г) Хәрефләр белән авазлар саны тигез булган сүзне билгеләгез.

а) *егет;*

ә) юрган;

б) төньяк;

в) табигать.

д) Рәт гармониясенә буйсынган сүзләр рәтен табыгыз.

а) җиһан, укучы, көнбатыш

ә) агачлар, атлар, ятимнәр

б) төньяк, суык, тимераяк

в) миңа, мисал, китап

е) Кайсы рәттәге сүзләрдә h хәрефе языла?

а) пө...тә, ...ат, рә...әт, ...алык

ә) шә...әр, ...әлак, ...ыял, ә...әмият

б) ...ава, зин...ар, да...и, ...әйкәл

в) ...өнәр ,...әтер, тари..., ил...ам

3. а) Һәр юлда артык сүзне билгеләгез.

1) ярдәм, ышанычлы, кешелекле

2) авылдаш, әңгәмәдәш, ватандаш

3) әдәпле, уңган, тупас

4) сәламләү, тәмамлау, исәнләшү.

б) Һәр юлда артык сүзне сызыгыз.

1) куян, карга, керпе, каз

2) вагон, вакыт, авыл, давыл

3) йозак, йомырка, йөрәк, йокы

4) һава, һәйкәл, шәһәр, тарих

4. а) Һәр юлда мәгънәләре буенча туры килә торган сүзләрне языгыз.

1) Фонетика _____ өйрәнә.

2) [а], [о], [у], [ы] — _____ сузыклар.

3) Калын сузыклы сүзләр _____ әйтелә.

4) [ә], [ө], [ү], [и], [э] _____ сузыклар.

5) Нечкә сузыклы сүзләр_____ әйтелә.

ә) Җөмләнең дәвам итеп бетерегез.

1) Авазларны ишетәбез һәм _____.

2) Хәрефләрне күрәбез һәм_____.

3) иг...тибар сүзендә ъ хәрефе _____.

4) яш...лек сүзендә ъ хәрефе _____.

5. а) Җөмләләрне укыгыз, орфографик хаталарны төзәтегез. Дөрес вариантны языгыз.

1) Урман – кешенең якын дус. — _____.

2) Ул үзенең матуры, гүзәллеге белән табигатькә ямь бирә. —

_____.

3) Әйе, урман матурда, файдалы да. — _____.

4) Ләкин урманга булыша, сакларга кирәк! — _____.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. 2019/2020 нче уку елында “Туган тел (татар теле)” һәм “Әдәбият (татар әдәбияты)” укытуның актуаль мәсьәләләре/ төз.: Шәмсетдинова Р. Р., Фәттахова Р. Ф., Гыйләҗева Л. Г. — Казан: ТРМҮИ, 2019. — 56 б.
2. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен ТР дәүләт теле буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Хадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2021. — 85 б.
3. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Хадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2020. — 32 б.
4. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2021. — 64 б.
5. Җамалетдинова З.И.Татар теле: туган телдә (татар телендә) башл. Гомуми белем бирү оешмаларының 2 нче сыйныфы өчен дәреслек. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013. — 127 б.
6. Имтихан өчен биремнәр (белем бирү эчтәлеге этномәдәни (татар) компонентлы белем бирү оешмаларында туган (татар)телдән имтихан үткәрү өчен методик тәкъдимнәр һәм үрнәк текстлар)/ төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г.– Казан: ТР МҮИ, 2019. – 45 б.
7. Сыйныфтан тыш эшчәнлекне оештыруның бер төре буларак олимпиада хәрәкәте Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. Казан: ТРМҮИ, 2020. — 52 б.
8. Татар теле буенча төп дәүләт имтиханына әзерләнү өчен биремнәр Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2020. — 47 б.

9. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының предмет һәм методика өлкәсендәге компетенцияләрен бәяләү өчен биремнәр Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2020. — 47 б.

10. Туган тел (татар телен) һәм әдәбиятны укытуда дәрестән тыш эшчәнлекнең роле / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Хадиева Г.В.. — Казан: ТРМҮИ, 2019 – 40 б.

11. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең 9 нчы сыйныф укучылары өчен “Туган (татар әдәбияты) әдәбияттан” эш программасы төзү өчен методик тәкъдимнәр Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. Казан: ТРМҮИ, 2020. — 48 б.

12. Фаттахова Р.Ф. Практический татарский язык: методическое пособие для изучающих татарский язык. – Казань: Татар. кн. Изд-во, 2012. – 176 с.

13. Фәттахова Р.Ф. "Белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү дәресләре". — Фәнни Татарстан, № 1, 2019. —109–114 б.

14. Фәттахова Р.Ф. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен ТР дәүләт теле буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр. Казан: ТРМҮИ, 2020. — 28 б.

15. Фәттахова Р.Ф. Рус төркемнәрендә татар телен укытуда коммуникатив технологияне куллану. — Сборник материалов Международной НПК «Правовые основы функционирования гос. языков в условиях дву- и многоязычия». – Казань: ИЯЛИ, 2019. — 198–200 с.

16. Фәттахова Р.Ф. Уку предметын үзләштерүнең предмет нәтиҗәләренә карата таләпләр нигезендә “ТР дәүләт теле буларак татар теле” предметы буенча белемнәрнең КҮМ”. — Казан: ТРМҮИ, 2020. — 42 б.

17. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005. — 160 б.